**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Төрекләр авылындагы үләннәрне чабу).

2. Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (материаллар сатып алу, Төрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); Төрекләр авылында территорияне чистарту; зират, үләннәрен чабу).

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.